СОВЕТ
ЭБАЛАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЯБАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ | КАРАР

12.05.2020 | Ябалак авылы | №8

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау буенча бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 26 статьясы, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау буенча бермандатлы сайлау округлары схемасын расларга (кушымта).
2. Ябалак авыл җирлеге Советының 2015 елның 8 маендагы «Ябалак авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау буенча бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» гы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга. Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат– телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: https://ebalak-kaybici.tatarstan.ru, Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән белән халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Ябалак авыл җирлеге Башлыгы М. Ф. Гыйзәтуллина

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Кайбыч муниципаль районы
Ябалак авыл җирлеге
Советының 2020 елның 12 нче
маендагы 8 нче номерлы карарына
кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯБАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНА ДЕПУТАТЛАР САЙЛАУ БУЕНЧА БЕРМАНДАТЛЫ САЙЛАУ ОКРУГЛАРЫ СХЕМАСЫ

1) **1 нче номерлы Беренче Май бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 94 кеше.
Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге территориясенең түбәндәге өлеше керә: Морза Бәрлебашы авылы территориясенең бер өлеше (Үзәк урамы, 5, 11 нче йортлар; Урман урамы, 4 нче йорт, Болын урамы 1, 3 нче йортлар; Беренче Май урамы так якта 5 нче йорттан 53 нче йортка кадәр һәм җеп якта 4 нче йорттан 54 нче йортка кадәр);

2) **2 нче номерлы Вахитов бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 94 кеше.
Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Бәрлебаш авылы территориясенең бер өлеше (Вахитов урамы, 2 йорттан 6га кадәр, Үзәк урамы, җөп һәм так яктан 1дән 66га кадәр йортлар, ) һәм Морза Бәрлебашы авылы территориясе өлеше (Беренче Май урамы, 1нче йорт, 3 нче йорт).

3) **3нче номерлы Җиләкле бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны - 93 кеше.
Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Бәрлебаш авылы территориясенең бер өлеше (Кояшлы урамы, 1нче йорттан 11гә кадәр йорт, Җиләкле урамы, 2нче йорттан 16га кадәр йорт, Вахитов урамы, 1нче йорт, 8нчедән 23кә кадәр йорт).

4) **4 нче номерлы Үзәк бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны 110.
Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Кече Кайбыч авылы территориясенең бер өлеше (Үзәк урамы җөп һәм так яктан 51нче йорттан 76нчы йортка кадәр, Галия Кайбицкая урамы, 1нче йорттан 26нчы йортка кадәр, Мәктәп урамы, 2нче йорттан 10нчы йортка кадәр).

5) **5 нче номерлы Күлле бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны 110.
Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Кече Кайбыч авылы территориясенең бер өлеше (Үзәк урамы, 2 нче йорттан 56 нчы йортка кадәр, Күлле урамы, 1 нче йорттан 11 нче йортка кадәр, Таулы урамы, 1 нче йорттан 6 нчы йортка кадәр).

6) **6 нчы Тукай бермандатлы сайлау округы**


Сайлаучылар саны 110.
Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Кече Кайбыч авылы территориясенең бер өлеше, Тукай урамы, 1нче йорттан 24нчегә кадәр, Урман урамы 1нче -2 нче йортлар, Бакча урамы 1нче йорттан 8 нчегә кадәр, Үзәк урамы, 78нче йорттан 82 нчегә кадәр, Таулы урамы так якта 7нче йорттан 27нчегә кадәр йортлар һәм җеп якта 6дан 18гәчә йортлар.

7) **7 нче Латыйф Хәмиди бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны 90.
Бермандатлы сайлау округына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге территориясенең түбәндәге өлешләре керә: Ябалак авылы территориясенең бер өлеше, Нагорная урамы, 5тән 8гә кадәр йортлар, Латыйф Хәмиди урамы, 18дән 37гә кадәр йортлар, Бакча урамы, 3тән 12гә кадәр йортлар, Зур Кызыл урамы , 2дән 21гә кадәр йортлар, Заречная урамы 1нче йорттан 10нчы га кадәр, Яр буе урамы 1нче йорттан 6га кадәр йортлар).

**График тасвирланышы**

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау буенча бер мандатлы сайлау округлары схемалары**




1 нче Беренче Май округы
2 нче Вахитов округы
3 нче Җиләкле округы
4 нче Үзәк округы
5 нче Күлле округы
6 нчы Тукай округы
7 нче Латыйф Хәмиди округы